# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче Сабай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

12.11.2024 №1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “ТР Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставының 23 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына таянып 2024 елның 12 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2025 нче елда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенә керүче Сабай торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Сабай торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Төзәтү, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (күмү урыннарын карап тоту: Сабай торак пунктындагы зират территориясен куаклардан һәм агачлардан чистарту).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 27 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 23 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 23 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче Сабай торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. «2025 нче елда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенә керүче Сабай торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Сабай торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Төзәтү, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (күмү урыннарын карап тоту: Сабай торак пунктындагы зират территориясен куаклардан һәм агачлардан чистарту) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/timershik адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен.

Халык җыенында рәислек итүче,
Тимершык авыл
җирлеге Башлыгы

А.Х. Хаҗиев